**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Советы**

# КАРАР

**15 ноябрь 2021 ел** **№ 49**

**Җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләләрне хәл итүдә торак пункт территорияләренең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләре бердәмлеге критерийларыннан чыгып Нурлат шәһәрендә гражданнар җыены үткәрелә торган территорияләр чикләрен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2008 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы, муниципаль берәмлек Уставының 23 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Нурлат шәһәрендә җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләләрне хәл итүдә торак пункт территорияләренең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләре бердәмлеге критерийларыннан чыгып үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин булган беркетелгән территорияләрнең чикләрен расларга.
2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Нурлат шәһәре Советы Рәисе А.С. Әхмәтшин

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2021 елның 15 ноябрендәге 49 номерлы карарына кушымта

**Җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләләрне хәл итүдә торак пункт территорияләренең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең мәнфәгатьләре бердәмлеге критерийларыннан чыгып Нурлат шәһәрендә гражданнар җыены үткәрелә торган территорияләр чикләре**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4.3 пункты нигезендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены Нурлат шәһәренең түбәндәге территорияләре өлешендә үткәрелергә мөмкин.

Халык мәнфәгатьләренең гомуми критерийларыннан чыгып, тиешле һәр территория шәхси торак йортлар урнашкан түбәндәге аерым урамнардан тора дип билгеләргә:

**1.1. «Шикәрчеләр» микрорайоны территориясе.**

Территориягә Маяковский (барлык йортлар), Карбышев (19-32 нче йортлар)урамнарында урнашкан шәхси торак йортлар керә.

**1.2. «Югары Нурлат» микрорайоны территориясе.**

Территориягә Новая урамында урнашкан (14-41 нче йортлар) шәхси торак йортлар керә.

**1.3. «Түбән Нурлат» микрорайоны территориясе.**

Территориягә Лесная урамында урнашкан шәхси торак йортлар (1-30 нчы йортлар)керә.

**1.4. «Төньяк» микрорайоны территориясе.**

Территориягә Халиков урамында урнашкан шәхси торак йортлар (1-38 нче йортлар) керә.

**1.5. «Көнбатыш» микрорайоны территориясе.**

Территориягә Сембер (йортларның җөп номерлылары), Интернационалистлар, Һадиев, Сафиуллин, Семенов, Андронов, Бакиров, Шоссейная урамнарында, Шоссейный, Бакиров, Семенов тыкрыкларының барлык йортлары керә.

**1.6. «Көньяк-Көнбатыш» микрорайоны территориясе.**

Территориягә Сембер (йортларның так номерлары), Юданов, Әхмәтов, Андреев, Кыямов, Виссарионов, Тихая, Чишмәле, Новостройки, Братская, Рябиновая, Имәнлек, Ипподром урамнарында урнашкан барлык шәхси торак йортлар керә.

**1.7. «Тимерьюлчылар» микрорайоны территориясе.**

Территориягә Көнбатыш, Полевая, Спартак урамнарында урнашкан барлык шәхси торак йортлар керә.